СОВЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан, Сабинский район, п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы, Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 202 от 21.02.2018
на № ________ от ________

# КАРАР

Саба муниципаль районының «Забота» халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү Фонды Советы составына үзгәрешләр кертү хакында

Саба муниципаль районының «Забота» халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү Фонды Советының кайбер әгъзаларының вазыйфаларыннан китүләре сәбәпле, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Саба муниципаль районының «Забота» халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү Фонды Советының составына Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының 2015 елның 17 декабрендәге 27нче номерлы карары белән (2017 елның 14 декабрендәге 189 номерлы редакциясендә) расланган «Саба муниципаль районының «Забота» халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү Фонды» Советының составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Комиссия составыннан Т.Г. Шәрәфиевны чыгарырга;

1.2. Г.Х. Хуҗинаны, Саба муниципаль район Контроль-хисап палатасы рәисен, Фондның Совет рәисе итеп Совет составына кертергә.

2. Әлеге карарны контрольлек итүне РФ агросәнәгать комплексы хезмәткәрләренең Татарстан Республикасы профсоюз оешмасының Саба район оешмасы рәисе Г.Р. Нигамәтҗановага йөкләргә.

Саба муниципаль районы Башлыгы — Р.Н. Минниханов

**Саба муниципаль районының «Забота» халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү Фонды Советы**

**СОСТАВЫ**

*2015 елның 17 декабрендәге 27нче номерлы карары белән расланган (2017 елның 14 декабрендәге 189 номерлы редакциясендә)*

| | |
|---|---|
| Хузина Г.Х. | Саба муниципаль район Контроль-хисап палатасы рәисе, Фонд Советы рәисе; |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Гатиятуллина Д.Р. | РФ агросәнәгать комплексы хезмәткәрләренең Татарстан Республикасы профсоюз оешмасының Саба район оешмасы баш бухгалтеры (килешү буенча); |
| Нигамәтҗанова Г.Р. | РФ агросәнәгать комплексы хезмәткәрләренең Татарстан Республикасы профсоюз оешмасының Саба район оешмасы рәисе (килешү буенча); |
| Тимерханова Э.З. | РФ социаль иминиятләштерү Фондының ТР буенча бүлегенең 8нче номерлы филиалы вакәләтлесе (килешү буенча); |
| Хуҗин М.М. | ТР хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының Саба муниципаль районындагы бүлеге начальнигы (килешү буенча). |